**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2025 елның 4 декабрендәге 4258 номерлы карары**

# Казан шәһәре Башкарма комитетының 2011 елның 7 декабрендәге 7835 номерлы «Казан шәһәре Башкарма комитеты каршында торак комиссиясе төзү турында»гы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Кадрлар үзгәрешләренә бәйле рәвештә һәм Казан шәһәре Башкарма комитеты каршындагы торак комиссиясе составына үзгәрешләр кертү зарурлыгына бәйле рәвештә **карар бирәм**:

1. Казан шәһәре Башкарма комитетының 2011 елның 7 декабрендәге 7835 номерлы «Казан шәһәре Башкарма комитеты каршында торак комиссиясе төзү турында»гы карарының (аңа Казан шәһәре Башкарма комитетының 2014 елның 28 мартындагы 1680 номерлы, 2015 елның 24 апрелендәге 1883 номерлы, 2016 елның 24 августындагы 3551 номерлы, 2018 елның 16 октябрендәге 5383 номерлы, 2018 елның 28 декабрендәге 6555 номерлы, 2020 елның 18 маендагы 1405 номерлы, 2020 елның 21 июлендәге 1951 номерлы, 2021 елның 12 июлендәге 1710 номерлы, 2023 елның 23 октябрендәге 3187 номерлы, 2024 елның 12 мартындагы 817 номерлы, 2024 елның 16 апрелендәге 1574 номерлы, 2024 елның 16 августындагы 3376 номерлы, 2024 елның 1 ноябрендәге 4583 номерлы, 2025 елның 11 июнендәге 1831 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) 1 номерлы кушымтасына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. комиссия составыннан Ю.Б.Трифонованы чыгарырга;

1.2. комиссия составына, комиссия әгъзасы итеп, Казан шәһәре Башкарма комитетының Торак сәясәте идарәсе башлыгы урынбасары Митрошенкова Елена Сергеевнаны кертергә;

1.3. комиссия әгъзасы Е.Н.Смагинаның вазифасы атамасын түбәндәге редакциядә бирергә: «“Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының Торак сәясәте идарәсе” муниципаль казна учреждениесенең

муниципаль торак фондын исәпкә алу һәм бүлү бүлеге башлыгы».

2. Әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары И.Ә.Гыйниятуллинга йөкләргә.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**